# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында" Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 7 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында" 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2007, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 пунктта "гражданнарга һәм" сүзләрен төшереп калдырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле $14^1$ пункт өстәргә:

"$14^1$) гражданнарга Татарстан Республикасында хезмәт базарының торышы, халыкны эш белән тәэмин итү һәм эшсезлектән яклау өлкәсендәге хокуклар һәм гарантияләр турында мәгълүмат, шул исәптән электрон рәвештә дә, бирәләр;".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 1 августы
№ 54-ТРЗ